**СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423181, РТ, Новошешминский район,
село Тубылгы Тау, ул. Молодежная, д.73,

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУБЫЛГЫТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423181,ТР, Яңа Чишмә районы,
Тубылгы Тау авылы, Яшьләр урамы, 73

тел.: (8-84348) 3-82-58, факс: (8-84348) 3-82-44, Tub.Nsm@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

“ 29 “ сентябрь 2018 нче ел № 44-104

## “ЯҢА ЧИШМӘ РАЙОНЫ ТУБЫЛГЫ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БИЛӘМӘЛӘРЕНДӘ ҮЗАРА САЛЫМ ҖЫЮ ҺӘМ КУЛЛАНУ БУЕНЧА РЕФЕРЕНДУМ КӨНЕН БИЛГЕЛӘРГӘ”

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлауга хокукы һәм референдумда катнашуга хокукы турында”гы Федераль законның, 12 нче июнь 2002 нче ел “67-ФЗ, 15 нче матдәсе нигезендә, шулай ук “Россия Федерациясендә үзҗитәкчелекне оештыру турында” Федераль Законның, 6 нчы октябрь 2003 нче ел № 131-ФЗ, 22 нче, 56 нчы матдәсе нигезендә, “Җирле референдум турындагы” Татарстан Республикасы законы 24 нче март 2004 нче ел, № 23-ТРЗ, 17 нче, 18 нче матдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы, “Тубылгы Тау авыл җирлеге” Уставнының 11 нче матдәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Тубылгы Тау авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 нче елнын 17 сентябере № 20 номерлы”Референдум үткәрүгү башлангыч бирү” турындагы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Тубылгы Тау авыл җирлеге Советының 2018 нче елнын 17 сентябере № 43-103 номерлы”Референдум үткәрүгү башлангыч бирү” турындагы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмш районы Тубылгы Тау авыл җирлеге Советы

**КАРАР** бирә:

1. Тубылгы Тау авыл җирлеге биләмәсендә, үзара салым җыю һәм куллану буенча, 2018 нче елның 18 нче ноябренә референдум көнен билгеләргә.
2. Референдумда каралачак сорауларны барларга:

“Сез , Тубылгы Тау авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән, 2019 нчы елга, 500 сум күләмендә үзара салым җыю белән килешәсезме?
Үзара салым түләүдән көндезге бүлектә укучы студентлар, Бөек Ватан сугышы ветераны һәм сугыш ветеранының тол хатыны, 1 нче группа инвалидлар азат ителә.

Үзара салым түләүдән җыелган акчалар Тубылгы Тау авыл җирлегендә түбәндәге хезмәтләр өчен кулланылачак:
-юлларны төзү һәм тәртиптә тоту, шулай ук юлларны кардан чистарту, җәй көне юл кырыйларындагы печәнне чабу;
-асылмалы һәм роторлы чапкыч сатыб алу;
-су кудыру скважинасының санитар зонасың әйләндереп алу һәм тәртиптә тоту.

ӘЙЕ ЮК".

3. Карарны "Яңа Чишмә" район газетасында бастырырга.
4. Карар "Яңа Чишмә" район газетасы битләрендә басырылган көннән үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә йөклим.

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципальрайоны Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы** **Ф. Ф. Исмагилов**